ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.07.2021 г. Заинск № 439

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында»**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында" 2021 елның 18 июнендәге 56 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының административ комиссиясен төзергә.
2. Расларга:

- Зәй муниципаль районының административ комиссиясе составын (1нче кушымта);
- Зәй муниципаль районының административ комиссиясе эш регламентын (2нче кушымта).

3. Зәй муниципаль районының административ комиссиясе вәкаләтләре чоры әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел тәшкил итә.
4. Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- «Зәй муниципаль районының административ комиссиясе составы турында» 2006 елның 07 мартындагы 57 номерлы карары (Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 29 гыйнварындагы 70 номерлы, 2007 елның 29 гыйнварындагы 70 номерлы, 2007 елның 03 маендагы 511 номерлы, 2008 елның 19 мартындагы309 номерлы, 2009 елның 11 июнендәге 924 номерлы, 2011 елның 03 февралендәге 226 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән);

- «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе составын яңа редакциядә раслау турында» 2014 елның 02 сентябрендәге 1908 номерлы карары (Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 12 гыйнварындагы 12 номерлы, 2016 елның 30 июнендәге 1365 номерлы, 2017 елның 09 февралендәге 152 номерлы, 2018 елның 04 декабрендәге 1779 номерлы, 2019 елның 18 гыйнварындагы06 номерлы, 2019 елның 31 октябрендәге 569 номерлы, 2021 елның 11 февралендәге 78 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән).

5. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

А.Ж.Ризванова
(85558) 3-12-14

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 06.07.
439 номерлы карарына
1 кушымта.

**Административ комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Галеев Эмиль Эдуард улы | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Садртдинов Роберт Рафаил улы | Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Ризванова Алия Җәүдәт кызы | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе баш белгече, комиссиянең җаваплы секретаре |
| **Комиссия әгъзалары** | |
| Кашапов Талгать Рәфәгать улы | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты баш белгече |
| Кобелева Елена Николаевна | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече |
| Кулагина Эльмира Наил кызы | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге баш белгече |
| Лоптова Татьяна Александровна | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе |
| Митянина Елена Александровна | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге әйдәүче белгече |
| Пукаева Ирина Николаевна | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге баш белгече |

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Т.А. Лоптова**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 06.07.
439 номерлы карарына
2 кушымта.

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы административ комиссиясенең эш РЕГЛАМЕНТЫ

Әлеге регламент Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы административ комиссиянең (алга таба – административ комиссия) эш тәртибен билгели.

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ комиссия Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) һәм «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2021 елның 18 июнендәге 56 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карары нигезендә төзелде.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турындаэшләрне карау өчен төзелә һәм даими эшли торган коллегиаль орган булып тора һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы чикләрендә башкара.

1.4. Административ комиссиянең бурычы-административ хокук бозу турында эшләрне һәрьяклап, тулы, объектив һәм үз вакытында карау, кабул ителгән карарның үтәлешен тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү.

1.5. Административ комиссиянең эшчәнлек вәкаләтләре срогы административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел дәвам итә.

1.6. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

1.7. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда

туктатылганда үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан әгъза урынына административ комиссиянең яңа әгъзасы бер ай эчендә билгеләнә.

1.8. Административ комиссиянең административ комиссиянең тулы исеме күрсәтелгән мөһере булырга мөмкин.

1.9. Административ комиссияне төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру.

2.1. Административ комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, административ комиссиянең җаваплы секретареннән һәм административ комиссия әгъзаларыннан (алга таба – административ комиссия әгъзалары) тора, алар Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнә (килешү буенча).

2.2. Административ комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

2.3. Административ комиссиянең персональ һәм сан составы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнә, ул 5 кешедән дә ким булмаган так санда булырга тиеш.

2.4. Даими штат нигезендә административ комиссия составына административ комиссиянең җаваплы секретаре керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары, әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган очраклардан тыш, административ комиссиядә җәмәгать башлангычында эшлиләр.

2.5. Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары буенча административ комиссиянең башка әгъзалары үз вазыйфаларын җирле бюджет акчалары хисабына даими түләүле нигездә башкара алалар.

2.6. Административ комиссия рәисе рәис урынбасарлары һәм административ комиссиянең җаваплы секретаре арасында вазыйфаларны бүлә, аларның функцияләрен Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә билгели.

2.7.Комиссиянең җаваплы секретаре булмаган очракта (эш сәфәре, чираттага ялда булу, авыру һ.б.) аның вазыйфаи вәкаләтләрен комиссия рәисе яисә аның вазыйфаларын башкаручы зат карары буенча комиссия әгъзаларының берсе башкара.

2.8.Административ комиссия рәисе административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасарының һәм административ комиссия җаваплы секретаренең квалификациясен күтәрү эшен оештыра.

2.9. Административ комиссия мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итә. Мөрәҗәгать итүчеләрнекабул итү тәртибе административ комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

2.10. Административ комиссия адресына гражданнардан һәм юридик затлардан кергән шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгатьләрне һәм шикаятьләрне исәпкә алу журналында теркәлә, карала һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда җаваплар җибәрелә.

2.11. Административ комиссия төзекләндерү, чисталыкны һәм тәртипне тәэмин итү өлкәсен контрольдә тота һәм Зәй муниципаль районы территориясендә хокук бозуларны кисәтү эшен башкара. Контрольдә тоту тәртибе һәм контроль тикшерүләр үткәрү буенча эш планы административ комиссия рәисе тарафыннан раслана.

2.12. Административ хокук бозулар буенча эшләр административ комиссиядә саклана, һәм алар 3 ел үткәннән соң исәптән төшерү турында акт нигезендә юкка чыгарылырга тиеш.

2.13. Административ комиссия эшчәнлеген яхшырту максатларында суд-арбитраж практикасына даими гомуми нәтиҗәләр ясала.

Суд-арбитраж практикасына ясалган гомуми нәтиҗәләрне исәпкә алып, законнарны өйрәнү һәм хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү эше оештырыла.

2.14. Административ комиссия тарафыннан билгеләнгән форма буенча хисап эше алып барыла.

Әлеге белешмәләр квартал саен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча тапшырыла.

2.15. Мөрәҗәгать итүчеләргә, законнарда каралган очраклардан тыш, карар чыгарылганчы, административ хокук бозулар турында эшләрне бирү тыела.

2.16. Административ комиссиядә мәгълүмати-белешмә эше алып барыла.

## 3. Административ комиссия утырышын чакыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Административ хокук бозулар турында эшләрне карау административ комиссия тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.2. Административ хокук бозулар турында эшләр административ комиссия утырышларында карала. Административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карарны административ комиссия рәисе кабул итә, ә ул булмаганда, административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар керүгә карап, рәис урынбасары тарфыннан кабул ителә, әмма айга 2 мәртәбәдән дә ким түгел.

3.3. Административ комиссия утырышлары административ хокук бозулар турында эшләрне карау срокларын үтәүне тәэмин итә торган вакыт аралыгы беләән уздырыла.

3.4. Административ комиссиянең җаваплы секретаре административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында административ комиссия әгъзаларына административ комиссия утырышына кадәр кимендә өч көн алдан хәбәр итә.

3.5. Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, рәис, рәис урынбасары һәм комиссия әгъзалары бу хакта административ комиссиянең җаваплы секретаренә, кагыйдә буларак,

административ комиссия утырышына кадәр бер көн алдан хәбәр итәргә тиешләр.

3.6. Административ комиссия утырышы, әгәр анда административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы була.

3.7. Административ хокук бозу турында эш буенча карар, билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.8. Административ комиссия утырышлары ачык булып тора. Аларда массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3.9. Коллегиаль орган карары буенча утырышлар ябык булырга мөмкин. Аларда комиссия әгъзалары, хокук саклау органнарының вазыйфаи затлары һәм махсус чакырылган затлар катнашырга хокуклы.

3.10. Административ комиссия утырышы вакытында кино -, видео-һәм фотога төшерү рәис рөхсәте белән башкарыла.

3.11. Административ хокук бозу турында эшне карау өчен билгеләнгән вакытта рәислек итүче утырышны ача, комиссия составын игълан итә, эштә катнашучыга хокук һәм бурычларны аңлата, утырышны алып бару тәртибен билгели, административ процесста катнашучыларның гаризалары, үтенечнамәләре бармы-юкмы икәнне ачыклый, утырыш белән җитәкчелек итә, эшнең барлык шартларын тулысынча ачыклауга ярдәм итә, утырыш барышында тиешле тәртипне үтәүне тәэмин итә.

3.12. Административ комиссия каравына кертелгән мәсьәләләр буенча материаллар суд практикасына күзәтү (гомумиләштерү) рәвешендә бирелә.

3.13. Административ хокук бозулар турында эшләрне карау чираты хәбәрнамәләр белән билгеләнә. Кирәк булганда, административ комиссия бу чиратны үзгәртергә хокуклы.

3.14. Административ хокук бозу турында эшне карау административ материалда бәян ителгән хәлләр турында рәислек итүче докладыннан башлана. Доклад тәмамланганнан соң, административ комиссия әгъзалары карала торган эшнең асылы буенча сораулар бирергә хокуклы.

3.15. Административ комиссиянең һәр утырышында административ хокук бозу турындагы эшне карау турында беркетмә алып бару мәҗбүри, ул җаваплы сәркатип тарафыннан башкарыла.

**4. Административ комиссия карары**

4.1. Административ комиссия карары рәислек итүче тарафыннан имзалана.

4.2. Бер үк вакытта утырышта катнашучы затларга һәм аларның вәкилләренә административ комиссия карарына шикаять белдерү тәртибе аңлатыла.

4.3. Чыгарылган карарның күчермәсе физик затка яисә физик затның законлы вәкиленә яисә юридик затның законлы вәкиленә расписка нигезендә тапшырыла йә күрсәтелгән карар чыгарылган көннән алып өч көн эчендә тиешле затларга җибәрелә.

4.4. Административ комиссия карарлары күчермәләренең үз вакытында тапшырылуын һәм җибәрелүен контрольдә тоту җаваплы секретарьга йөкләнә.

4.5. Административ комиссиянең закон көченә кергән карарын үтәү Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

4.6. Административ комиссия карарларына карата шикаятьләр яисә протестлар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә карала.

## 5.Административ хокук бозуларны профилактикалау

5.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында административ комиссия үз эшчәнлеген эчке эшләр органнары, суд приставлары федераль хезмәте идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән яраштыра.

5.2. Административ комиссия рәис раслаган график нигезендә күчмә утырышлар үткәрә, шул исәптән муниципаль район җирлекләрендә дә.

5.3. Административ комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре алып бару юлы белән профилактика эшен оештыра.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Т.А. Лоптова**